# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ
**(III чакырылыш)**

егерме бишенче утырыш

# КАРАРЫ

12 декабрь 2018 ел **№ 159** Теләче авылы

Татарстан Республикасының Теләче районы территориясендә сәгатенә 6 тонна җитештерүчәнлекле табигый газны сыекландыру комплексы (КСПГ-6) төзелеше өчен («ТопГаз» ҖЧҖ, Теләче муниципаль районы) арендага бирелгән җир участогына аренда түләвеннән азат итү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәләрне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән 131-ФЗ санлы Федераль законга, «Россия Федерациясендә капитал салулар формасында инвестиция эшчәнлеге турында»гы 1999 елның 25 февралендәге 39-ФЗ санлы Федераль законга, «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында»гы 1998 елның 25 ноябрендәге 1872 санлы Татарстан Республикасы Законына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының 2018 елга Инвестиция меморандумын раслау турында»гы 2017 елның 29 декабрендәге 1079 санлы карары белән расланган «2018 елга Татарстан Республикасы Инвестиция маморандумына үзгәрешләр кертү турында»гы Татарстан Республиксы Министрлар Кабинетының 2018 елның 15 августындагы 670 санлы карарына, «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы» муниципаль берәмлек Уставына туры китереп, «ТопГаз» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьнең 2018 елның 05 декабрендәге 01/29 санлы хатын караганнан соң, Теләче муниципаль районы Советы **карар бирә:**

1. 2019 елның 1 гыйнварыннан 2023 елның 31 декабренә кадәр «ТопГаз» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьне - ИНН 1619007116 гомуми мәйданы 79300 кв.м., кадастр номеры 16:40:100110:90 булган җир участогы өчен аренда түләвеннән азат итәргә. Рөхсәт ителгән файдалану төре: «сәнәгать, энергетика, транспорт, элемтә, радиотапшырулар, телевидение, информатика объектлары, космик эшчәнлек, саклану, куркынычсызлык буенча һәм башка махсус объектлар урнаштыру өчен».

2. Җир өчен аренда түләвенә ташламалар куллануга арендаторның Татарстан Республикасы Инвестиция меморандумына кертелүе нигез булып торуын билгеләргә.

3. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән җир участогы арендаторы, җир участогын рөхсәт ителгән төр буенча кулланмаганда, җир өчен аренда түләвен тулысынча кертә.

4. Карарны гамәлдәге законнар нигезенлә бастырып чыгарырга.

5. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Теләче муниципаль районы башкарма комитетына (И.Х. Хәмидуллин) йөкләргә.

Теләче муниципаль
районы башлыгы И. Ф. Зарипов